


Кадерле дуслар! Сезне чын кvнелдән Боек Жинv бәйрәме белән тәбрик итәм. Жинv алып килгән май иртәсеннән кvп еллар узуга карамастан, илебез солдатларынын батырлыгы халык хәтерендә мәнге калачак. Азатлык очен башын салганнарны, сугыштан сон яраларыннан вафат булганнарны истән чыгармау, исәннәрне хормәтләv – һәрберебезнен изге бурычы. Кызганыч, вакыт шул тарихи вакыйгалар шаһитларын арабыздан алып китә, vзләрен аямыйча, зур фидакарьлек кvрсәтеп, дошман уты астына кергән ветераннарыбыз сафы коннән-кон сирәгәя. Без аларга тынычлык алып килгәннәре, тормыш тәжрибәсе, кимемәс рух ныклыгы, ватанпәрвәрлекләре очен чиксез рәхмәтле.

Илебез кvге аяз булсын, киләчәк буын сугыш дигән афәтне белмәсен. Тынычлык, бәхет-шатлык, исәнлек-саулык сезгә, хормәтле ветераннарыбыз. Сезнен буын – жинvчеләр буыны – кvпме авырлыклар, ачлык-ялангачлык, ин газиз кешеләрен мәнгегә югалту бәрабәренә доньяны фашизмнан коткарган. Сез кvрсәткән батырлык, илсоярлек, ватанпәрвәрлек vсеп килvче яшь буынны тәрбияләvдә зур роль уйный. Шушы якты, матур коннәрдә сезгә сәламәтлек, бәхетле һәм тыныч картлык телим, якыннарыгызнын кадер-хормәте vзегезне һәрвакыт озата килсен.{jcomments on}